МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

19 декабрь 2024 ел

№ М 605

Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы Карары белән (Шәһәр Хакименең 2015 елның 24 февралендәге М 58 номерлы, 2016 елның 1 февралендәге М 34 номерлы, 2018 елның 29 июнендәге М 293 номерлы, 2021 елның 14 маендагы М 186 номерлы, 2022 елның 14 мартындагы М 94 номерлы, 2022 елның 17 июнендәге

М 254 номерлы, 2022 елның 2 ноябрендәге М 484 номерлы, 2023 елның 24 мартындагы М 113 номерлы, 2023 елның 3 октябрендәге М 454 номерлы, 2023 елның 20 декабрендәге М 604 номерлы, 2024 елның 20 февралендәге М 72 номерлы, 2024 елның 11 июлендәге М 355 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәре чикләрендә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры (Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына 1 нче кушымта) нигезендә Шәһәр Советының 2008 елның 13 декабрендәге 36/9 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфалары:

1) Башкарма комитет Җитәкчесе;
2) Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары;
3) Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары;
4) Хаким (Шәһәр Советы) аппаратының эшләр идарәчесе;
5) Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе;
6) Башкарма комитетның район Хакимияте Башлыгы;
7) Башкарма комитетның эшләр идарәчесе;
8) Аппарат Җитәкчесе урынбасары;
9) Хаким (Шәһәр Советы) аппаратының идарә башлыгы;
10) Хаким (Шәһәр Советы) аппаратының бүлек (мөстәкыйль) башлыгы;
11) Башкарма комитетның идарә башлыгы;
12) Башкарма комитетның бүлек (мөстәкыйль) башлыгы;
13) Район Хакимияте Башлыгы урынбасары;
14) Район Хакимияте аппараты җитәкчесе;
15) Башкарма комитет идарә башлыгының беренче урынбасары;
16) Башкарма комитетның идарә башлыгы урынбасары;
17) Башкарма комитетның бүлек (мөстәкыйль) башлыгы урынбасары.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев